
Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ДЕКАБРЬ * 2024 * КАЗАН

12

Сергей КОКАРЕВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Игорь КИЙКО



Алмаз ХӘМЗИН

ИЛ АҢЫ

Күз алдыма килә балачагым:
Бер гөнаһсыз үткән елларым,
Һаваларга очкан хыялларым,
Максатларым, изге уйларым...

Төшләр күреп төнлә саташканым,
Җеннәр белән нык сугышканым.
Тик беркайчан ярдәм сорашмадым,
Җиңелсәм дә, юк, акланмадым.

Еламадым, шыңшымадым һичбер,
Борчымадым әти-әнине.
Мин патриот буласы кеше –
Саклаучысы туган илемне!

Еллар үтте, буйга җиттек менә,
Әйе, гадел булып үстек без.
Үзгәрде дөнья – кешеләр башка –
Әллә без дә хәзер бик мәнсез?..

Әнә берәү вертолётта очып,
Сабантуйга бара, күрәмсез...
Безгә монда вертолётта түгел,
Җәяү булмый йөреп, түләүсез...

Бәйрәмнәр күп – санап бетергесез:
Байлар шулай элек көн күргән.
Мин сайлаган депутат та баеп,
Кара, нинди корсак үстергән!

Кемгә бәйрәм, безгә һаман шул хәл:
Әйбәтләнә, дибез тормышлар –
Һәр түрәнең хәзер үз "кесәсе",
"Булдыралар!" – бигрәк тырышлар!

Без язабыз элеккечә мактап,
Яшәешнең алга баруын.
Артка китүен әйтеп карасаң,
Эшеңнән бар коры калуың...

Инде тирә-юньдә каргалар да
Каркылдамый башлады.
Җырчыларның җырлавыннан өркеп,
Сандугачлар сайрамый башлады.

Тукраннар да рәтләп тукылдамый,
Тотлыгалар хәйран, чокынып.
Кай милләтләр – телен оныткannар
Кайчагында куя чукынып.

Ярлы-ябагай танымый үзен,
Әйтмәс берчак диеп, хәерче.
Әйтерсең лә ул бу илдә хуҗа,
Патшаларны хәтта Җиңүче!

...Искә төшә байтак уйланганда
Һәр мизгеле үткән гомернең.
Кызганамын янәшәмдә йөргән
Адәмнәрнең белеп кемлеген...

Әле дә сугышам "җеннәр" белән,
Алар хәзер өнгә чыктылар.
Чыктылар да минем хыялларны
Тагын менә утка тыктылар...

Шулай, шулай – сер бирмәскә һич тә,
Дөнья бармас һаман гел болай...
Без – гаделләр – запастагы гаскәр...
Ил аңы алга өнди бугай...
Әйе! Дөньяны үзгәртү кулай!

ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле «Чаян»! Нинди дә булса товарга бәя күтәрелү белән, акыллы башлы аналитиклар шундук моның сәбәбен аңлата башлыйлар. Вариантлары күп, әмма нәтиҗәсе бер генә: базар бит янәсе, шуңа күрә бәяләр үзгәреп тора...

М. ФӘҺИМОВ

ТҮБӘН КАМА

– Бәяләрнең үзгәрүе – аңлашыла. Әмма нигә соң алар һәрвакыт арту ягына үзгәрә? – дип уйга калды Шомбай ага, укучыбызның хатын укыгач.

Владимир СОЛДАТОВ

Галия ГАЙНЕТДИНОВА

АКЫЛЛЫ КИҢӘШЛӘР

Алга бар, артка әйләнеп карарга онытма.

Күңелең изгелек өләшсә, көткәнең игелек булыр.

Нәселең адашмасын дисәң, яхшы эз калдыр.

Туганың бәласенә күз йомма, ул – уртак бәла.

Сүзеңне акыл белән үлчә.

Атның дилбегәсен тота белгән, тормыш дилбегәсен дә оста тотар.

Җиңүгә ирешәсең килә икән, башта үзеңне җиңәргә өйрән.

Матурлыкны ямьсездән дә табып була.

Сүзеңне ишеттерергә теләсәң, кычкыру мәҗбүри түгел.

Үзең сөя белмәсәң, сөю өмет итмә.

Бөек булам дип биеккә менмә.

Кешеләр кайгы кичергәндә бәйрәм ясама.


Кечкенә әйбердән дә бәхетле була бел, чөнки кемдәдер анысы да юк.

Серле бул, керле булма.

Күлмәгеңә тап төшсә дә, вөҗданыңа тап төшмәсен.

Тормыш яхшы якка үзгәргән саен, кешеләрнең яхшы сыйфатлары югала бара.

Бер яклы сөюнең дәвамы юк.





Сергей КОКАРЕВ

Куркыныч сакчылар

Ничек тиз үзгәрә бу тормыш дигәннәре! Элек бит ничек иде: караңгы тыкрыкта берәр шикле бәндә юлыңа төшә дә, ай яктысында пәкесен ялтырата – һәм менә сиңа кеше милкен ачык рәвештә үзләштерү, гади итеп әйтсәк, талау. Хәзер исә мондый кара гамәлләр башкару өчен берниндн караңгы урам да, пәке ялтыравы да, кот ала торган чырай да кирәк түгел – кесә телефоныннан шалтыратып алу җитә. Дөрес, телефон җинаятьләренең алга китүе сәбәпле, гражданнар һәр шалтыратуга ышанмый башладылар. Әмма аферистлар кеше психологиясен Фрейд буенча өйрәнгәннәр, күрәсең – адәм баласының иң якты хисләренә һәм иң кара уйларына турыдан-туры бәрәләр. Мәсәлән, соңгы вакытларда еш кына "ФСБ хезмәткәрләре" элемтәгә чыга башлады. Моны аңларга була: ГПУ, КГБ кебек хәреф тезмәләренә карата ихтирам, хәтта курку хисе без – кешеләрнең канына сеңгән. Органнарга ярдәм итү теләген дә читтә калдырып булмый. Ә инде шәхсән сиңа, исем-отчество белән мөрәҗәгать иткән чакта бигрәк тә!


Казанда яшәүче 63 яшьлек пенсионерны шундый уенга тартып кертканнәр. "Яшерен фронт көрәшчеләре" аның счётларыннан күрше дәүләткә террорчылар өчен акча күчерергә тырышу турында хәбәр иткәннәр. Бу кабахәтлеккә киртә куяр өчен аларга ярдәм кирәк булачак – счётлардагы суммаларны кәгазь акчага әйләндереп, куркынычсыз счётка күчерү өчен яшерен рәвештә аларның хезмәткәренә тапшырырга. Патриотик рухта фикер йөртүче гражданин, артык төпченеп тормыйча, алты банктагы счётларын бушатып, тиеш кешегә илтеп тапшырган. Ләкин менә яңа реквизитларны "чекистлар" хәбәр итәргә онытканнар. "Гражданлык бурычын үтәү"нең үзенә 18 миллионга төшкәнен беркатлы абзый соңыннан гына аңлаган.

Ярый, гади кешене төп башына утырту бик катлаулы булмагандыр. Ә менә "махсус хезмәт" үтенечләрен үтәргә дәүләт органнарында эшләүчеләр алына икән – монысы инде бераз гаҗәпләндерә. Шул ук "террорчыларны финанслау" белән куркытып, Казанда дәүләт оешмаларының берсендә бүлек җитәкчесе булып эшләүче ханымны "чишендергәннәр". Аның шәхси акчаларын "конфискацияләү" өстенә, "хезмәткәрләр" аны кредитлар алырга һәм фатирын сатарга мәҗбүр иткәннәр. Кайгыртучан ирләр аны таксида гына йөрткәннәр, риэлтор табып биргәннәр һәм акчаны коткару буенча махсус операция вакытына фатир табып биргәннәр. Анда ул ике атна буе эшнең тәмам булуы турында хәбәр көтеп утырган, ләкин юкка. Өч хәрефтән торган оешма хезмәткәрләре белән аралашып, хатын 15 миллион сумнан һәм фатирыннан колак каккан. Полициягә мөрәҗәгать итәргә туры килгән.

Ә менә Алабугада яшәүче хатынның күп нульле счётлары булмаган. Әмма бу да аны бөтен җирдә калкып чыгучы "махсус структура" хезмәткәрләреннән саклап кала алмаган. Башта башлыгыннан аның финанс кагыйдәрен бозу очраклары ачыклану турында хәбәр килә. Аннан соң ниндидер "ФСБ майоры" шалтырата һәм кредитлар алып, акчасын күрсәтелгән счётларга күчерү турында күрсәтмә алына. Ханым көч-хәл белән миллионнан аз гына артык сумма җыеп, аны билгесез юнәлеш буенча җибәрә. Ә "майор" исә, бу бичарадан шуннан артыгын сыгып булмаячагын аңлап, мыштым гына юкка чыга.

Мондый очраклар Татарстанда гына дистәләп җыела. Шунысы кызык: шалтыратулар чын махсус органнар номерларыннан килә – бүгенге көндә номерларны алыштыру катлаулы нәрсә түгел. Чын хезмәткәрләр белдерүенчә, дәүләт иминлеге хакына алар гражданнардан күп нәрсә таләп итә алалар. Ә кешеләрнең шәхси акчалары белән эш итү тыела. Ә безнең очракта зыян күрүчеләр мошенникларга аларны үз теләкләре белән тапшырганнар. Бөтен акчаны эшләп табу мөкин түгел, ә булганын югалту җиңел, дип, юкка гына әйтмиләр бит.


Людмила САФИУЛЛИНА



Михаил ЛАРИЧЕВ



Виктор ФЁДОРОВ





• • •

Чагыштырма теориянең дөреслеген раслауга бер дәлил: әгәр дә туташ парковкадан үзенең кечкенә “Матиз” машинасын алып китә икән, бушап калган урынга ике “Джип” машинасын сыйдырырга була.

• • •

– Ирегез нәрсә белән шөгыльләнә?

– Ул хатын-кызларны матурлый.

– Ирегез әллә хирург яки косметологмы?

– Шәраб заводы директоры.

• • •

Әгәр яңа гына тоткан сельдь балыгын тиз арада сатып бетерә алмасалар, аны катырып саталар. Шуннан соң яңа гына катырылган, ныгытып катырылган, җиңелчә тозланган, төргән килеш һәм иң ахырдан тун астында (под шубой) килеш ясап саталар.

• • •

– Кадерлем, шулхәтле теләп, синнән бала табасым килә.

– Аптырарлык сәбәп юк, минем элеккеге никахтан икәү, кайсысын телисең, шунысын ал.

• • •

Нәрсәгә миңа әллә нинди гаджетлар һәм җайланмалар? Янәмәсе, алар минем ун мең адым атлаганымны чутлый. Тезем үз хәлен һәрвакыт белдереп тора ләбаса.

• • •

ГАИ инспекторы машина туктата, ә руль артында – аның элеккеге укытучысы:

– Исәнмесез, Наилә Зиннуровна, ручкагызны алыгыз әле, кәгазьгә йөз мәртәбә болай дип языгыз:

“Мин бүтән беркайчан да юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозмаячакмын...”

• • •

Пассажир стюардессадан сорый:

– Әйтегез әле, самолет экипажы тәҗрибәлеме?

– Тәҗрибәле. Ике тапкыр бер двигательдә һәм бер тапкыр бер канатта очтык.

• • •

Шәһәребездәге һава торышы турында кыскача: бозланган юлда таеп, сулы чокырга егылдым. Пычракка һәм үләнгә буялдым.



ИРЕШЕП БУЛМАСЛЫК КАБАЛА

Татарстан ипотека алу мөмкинлеге буенча регионнар арасында 39 нчы урында булып чыккан. Ипотека кабаласын каплау өчен ике эшләүче кешенең хезмәт хакыннан уртача 62 процент китә. Бу күрсәткеч Россия буенча 54% һәм хәтта 56% тәшкил иткән Мәскәү күрсәткеченнән дә югарырак. Татарстан буенча айлык түләүнең күләме – 75 мең сум. Тикшерүләр буенча, гаиләләрнең 12,3% ы гына ипотеканы тарта ала.

РУЛЬДӘГЕ "КУЯН"НАР

М 12 түләүле трассасында иң күп "куян"нар саны Чуаштан һәм Татарстанга караган өлешләрендә икәне ачыкланган. Монда машина йөртүчеләрнең 4% ы алып куелган йә томаланган номерлар белән элдертә икән. Бушлай йөрергә яратучыларның санын киметер өчен, якын вакытларда юлдан файдаланучыларның базасын төзергә һәм автомобильләрнең "цифрлы күчермәләрен" булдырырга җыеналар.

РИЗЫК ӨРӘКЛӘРЕ

Республиканың кибет киштәләрендә "өрәк" фирмалардан килгән туклану продуктлары барлыкка килде. Товарлар ялган адреслар белән билгеләнә һәм билгесез кешеләр тарафыннан җитештерелә. Анда нәрсә болгатылганын "җитештерүчеләр" үзләре генә белә. Мондый ризыклар исемлегенә Туладагы "Молпром" фирмасының сөт продукциясе, Ульяновскидан "Печкино" кондитер әйберләре һәм Самарадагы ит белән шөгыльләнүче "ЛМ-Экспорт" компаниясе товарлары керә. "Өрәк"ләрнең тулы исемлеген Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсенең сайтында табарга була.

ЮГАЛГАН ТАБИБЛАР

Татарстанда дүрт ел эчендә өч йөз дипломлы табиб "югалган". 2019–2023 елларда юллама алган 579 студенттан бары тик 154 кеше генә эшкә урнашкан, 262 белгеч аспирантурада укуын дәвам иткән, 13 е декретта утыра, ә 150 яшь табиб эзсез югалган. Аспирантура белән дә шундый ук хәл: дүрт ел эчендә аны 792 кеше тәмамлаган булса, ак халат киючеләр саны бары тик 667. Ә сез хастаханәләрдәге чиратларга зарланасыз...


СУСЫЗ ЮЛСЫЗЛЫК

Түбән Кама районы Борок авылында яшәүче күп балалы гаиләләр ун ел юл салу һәм сууткәргеч сузуны көтеп яшиләр. Шушы вакыт дәвамында алар бары тик вәгъдәләр генә ишетәләр. Күпләр бирелгән мәйданнарын үзләштерә дә алмый – чөнки анда яшәү мөмкин түгел. Кызганыч, бу бердәнбер хәл түгел. Республика буенча мондый җирләрнең бары тик 2,5–3% кына үзләштерелгән. Сәбәбе – яшәү өчен шартлар булмау.

Михаил ЛАРИЧЕВ



Алексей МАМАЕВ



Булат РАВИЛОВ

АЛТЫН ӘРЛӘН

Күптән түгел интернетта табигатьнең яңа могҗизасы чалынып китте – әрләң. Гади түгел – алтын. Чатта утыра һәм барысына да үзенең пәйда булуы белән алтынга күмәчәген вәгъдә кыла. Әлбәттә, аны кем тота ала. Сез нәрсә уйлыйсыз инде? Белдекле һәм акыллы кешеләр бу әрләнне тотарга ашкынды.

Менә, мәсәлән, бер яшь кеше. Көне буе өендә утыра һәм көтә. Җаваплы эш, әлбәттә. Утыра егет, мониторга текәлгән, һәм уйлый, аңа уңыш ничек килә. Кнопкаларга баса, битләрен үзгәртә. Кайчагында хәтта чәе дә суынып бетә. Әмма ул түзә. Төп максат – кирәкле мизгелне ычкындырмау.

– Менә әрләң килеп чыгар, – дип уйлый аучы, – барысы да җайланыр! Машина сатып алырмын, диңгезгә китәрмен. Ә бәлки әле, бизнес ачып җибәрермен! Билгеле, моның өчен эшләргә кирәк, әрләң булгач нигә шулхәтле интегергә?

Шул арада тирә-юньдәге кешеләр үзгәреш сизә башлыйлар. Күршесе, уңган кеше, килә дә:

– Син, ни, күптәннән фатир өчен түләмәгән. Бәлки сиңа эшеңә кайтырга кирәктер кабат?

– Нигә миңа синең эшең? Хәзер әрләң килеп чыгар да барысы да җайланыр. Син үзең дә минемчә эшләп кара!

Инде менә уңган-булган күршесе дә әрләң көтеп утыра. Бөтен күршеләре көтә: кайсы мобильнигыннан, кайсы ноутбуктан. Барысы да бер булып "инвесторлар". Эшкә берсе дә йөрми, чәйләре дә суына. Кайберәүләре кичке ашны да ташлавын әйтә – әрләнне качырудан куркып. Көннәр, атналар үтә. Әрләң һаман юк, халык көтә дә көтә. Экран каршында йоклыйлар – үзләренең бәхетен качырмас өчен. Инде йөзләре саргайган, күз кырыйларында сырлар. Ләкин өмет һаман кимеми! Әрләң генә качкан да киткән. Программаны япканнар дигән хәбәрләр таралган – барысына да уңышлар теләгәннәр дә бетерткәннәр. Ә халык утыра һаман акаеп:

– Эшли башламый булмас ахрысы? Фатирга да түлисе бар, ашыйсы да килә.

Әмма тынгысыз егет җүләр түгел, яңа чат тапкан. Әйтәләр икән, анда әрләң түгел, ә янут бәхет өләшә, ди. Инде монысы ялган түгел – бәхет китерә икән! Менә утыра безнең герой шуны көтеп. Янут, әлбәттә, әрләннән акыллырак. Шулай да, бәлки, бераз көтәргәдер яки эшләсәң яхшырак булыр…

Вячеслав ШИЛОВ





Михаил ЛАРИЧЕВ



Тишек Көпчәк

Йосыф ФАТКЫЛОВ

КИЧКЕ АВТОБУС

Казанда кич – автобусларда урын өчен көрәш бара торган вакыт. Син монда гади пассажир гына түгел, "Транспортта исән калу" реалити-шоуында катнашучы.

Менә Дәрвишләр бистәсенә йөри торган шыгрым тулы автобус. Тәрәзә төбендә наушниклы егет утыра, телефоныннан күзен алмый. Тукталыштан сумкаларын асып, әби керә. Пассажирлар урыннарыннан да кымшанмый. Егетнең исе дә китми аның керүенә.

Әби (тамак кырган булып):

– Улым, урын бирче!

Егет утыруын белә, үзе ниндидер көйгә башын чайкый. Пассажирлар бер-берсенә күз төшергәлиләр һәм пышылдашалар.

Әби:

– Элек яшьләр урын бирәләр иде. Хәзер берәүләрдә наушниклар, икенчеләрендә телефон. Кая тәгәри бу дөнья! Таксига гына утырып йөрисе калды.

Яшь егет янына кондуктор килә.

Кондуктор:

– Бәлки урын бирерсез?

Егет (наушнигын салып):

– Гафу итегез? Мин ишетмәдем.

Кондуктор:

– Ә мин ишетәм! Әбигә урын бирегез.

Егет әбигә күз кыскан булып:

– Гафу, бөтенләй томаланганмын, сизмәдем.

Әби:

– Борчылма, балакай. Башка вакытта игътибарлырак бул!

Егет баш игән була һәм ниндидер геройлык эшләгән кыяфәттә тагын музыка тыңлауга чума.

Әби (егеткә карап):

– Кара, ничек тиз төзәлде! Вакытында шелтә белдергәч.

Егет:

– Әйе, әбекәй, мин дә соңгы тукталышка хәтле барам...

Әби:

– Хәзер мәктәп тә, әти-әни дә тәрбия белән шөгыльләнми. Гел интернетта барысы да...

Егет:

– Әле төшмибез. Әйтермен кайчан чыгасын... Рәхмәт әйтеп тормагыз инде, әби...

Валентин ДРУЖИНИН



Александр ШУЛЬПИНОВ





Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

ЯҢА ЕЛ КАРШЫЛАУ

– Ничек, хатын, быел Яңа ел бәйрәмен кемгә барып каршы алабыз?

– Белмим шул. Шалтыратып кара ел саен бара торганнарга.

– Шалтыраткан идем. Без өйдә булмыйбыз шул, кунакка барабыз, диделәр.

– Кайсыларына шалтыраттың?

– Шул инде, 31 декабрьдә бара торганнарына.

– Ә икенчеләренә? Икенче көнне бара торганнарына?

– Алары да өйдә булмыйбыз, кунакка барасыбыз бар, диделәр.

– Менә бит нинди кешеләр. Бәйрәмдә бер өйләрендә утырмыйлар. Рәхәт иде ичмасам, шуларга гына барып, өстәл әзерлисе булмагач. Бер торт күтәреп барасың да беренче көнне, икенче көнне дә шуны ук күчтәнәч иттереп башкаларга күтәреп барасың...

– Шуны укмыни?

– Әйе, алар бит үзебезгә шуны күчтәнәч итеп биреп җибәрәләр. Күп акча да тотасы булмый.

– Ярар, алай булгач, икәү генә өйдә утырырбыз.

– Әйе. Тәмле ризыклар әзерләрмен, деликатеслар алырбыз...

– Табынны мул итеп әзерлә. Кеше ашатасыбыз юк. Берүзебез рәхәтләнеп бәйрәм итәрбез.

31 декабрь кичен болар Яңа ел бәйрәмен каршы алырга җыенып йөриләр... Берзаман ишеккә шакыган тавыш ишетелә.


– Хатын, карале, кем йөри икән анда?

– Кем йөрсен бу вакытта? Ялгыш шакыйлардыр...

Кабат шакыганнан соң ире үзе ишек ачарга була... һәм ачып җибәрү белән, үзләре ел саен кунакка йөргән дусларын күрә. Кулларында торт.

– Без сездә Яңа елны каршы алырга булдык. Менә күчтәнәч тә алдык, буш кул белән килгәнче, – дип сөенеште кунаклар.

– Бетте бәйрәм. Хәзер боларны сыйларга туры киләчәк... – дип, теш арасыннан сытып чыгарды ире...





ШӘМГУН

ДӘВАХАНӘГӘ БАРДЫМ

Авырып түгел инде. Хатыныма түләүсез дарулар яздырып алырга. Ныгытып йөри ала торган булса, үзе генә дә барыр иде. Ярый әле мин исән-сау – сырхау кешене интектереп йөрисем килми. Сәламәтлегем дә әле хәйран – Аллага шөкер, димен.

Беләм, анда барып кайткан кешеләр кайчагында үзләре дә аяктан егылалар – өйгә кайтып авасы гына кала. Ул чират, ул авыручылар, көтүдәге салкын тигән сарыклар кебек корык-корык ютәллиләр, төчкерәләр. Битләрен бияләйме шунда, яулыкмы, марлямы каплап йөткерүләреннән качып котыласың... Күзләрендә – яшь, ялварулы кыяфәтләрендә "гафу итегез, зинһар өчен!" дигән үтенеч.

Безнең илдә генәдер мондый хәл. Югыйсә бит авыру чирләп китсә, дәваханәгә барырга тиеш түгел, өенә табиб чакыртып дәваланырга тиеш. Ул аның хәлен аңлап, йә даруын яки башка әмәлен табып, терелтү эшен башларга бурычлы. Юк, теге вирус төялгән гәүдәсен җыеп приемга бара, ә аңа: "Талоның бармы?", "Чиратка бас!" диләр. Утыра инде, мескен, кабинеттан чыгарып биргән температура үлчи торган градусникны култык астына кыстырып, чакырганнарын көтеп – уттай янып.

Шулчак ишек төбенә җыелган чираттөркеменә бер артист килеп кушылды. Шактый популяр артист – исемен генә оныттым. Тора бу тора, тора инде, нишләсен, утырып торырга урын юк бит. Вакыт үтә, югыйсә врач янына кереп чыгучылар да бар, ләкин чират кимеми, киресенчә, арта гына. Аптырагач, кайберәүләр моның янына килеп, кул биреп күрешә башладылар: "Синме бу?" – диләр. "Әйе, мин!" – ди бу. Исемен әйтми. Күрешүчеләр дә исемең ничек әле синең дип сорарга кыймыйлар. Инде байтак вакыт үтте – сәгатьтән артык бугай (ике сәгать булмаса). Ниһаять, артист көлдерә үк башлады.


"Монда халык (дәваханәдә дип әйтүедер инде) безнең концертларга йөргән халыктан да күбрәк икән!" – дип куйды. Әй, көлде дә инде шундагы кешеләр. Ютәлләүләре дә тынды.


Нәрсә булды дигәндәй, күрше кабинеттагы врачлар да, эшләрен ташлап, коридорга чыктылар. Кайберәүләренең йончыган йөзләре ярым ачык ишектә калыкты. Әйе, үзем дә дәваханәгә керү белән врачларның талчыккан йөзләрен, авыруга сабышкан кыяфәтләрен күреп хафаланган идем...

Көлү катыш гөр килүгә тагын бер хәл сәбәп булды. Врачларның берсе әллә артистны таныпмы: "Исәнмесез?" – диде.

Артист җавабында: "Авырмыйсыздыр бит?" – дип әйтте. – Бөтен дәваханәгез белән!.. – дигәнен дә өстәде.

Рәхәтләнеп көлештеләр – авырып утыручыларның да хәле җиңеләеп китте...







Михаил МИХАЙЛОВ

Сөенче

– Исәнмесез, мин – Кыш бабай...

– Күрәм, ашыгыч ярдәм табибы түгел...

– Чанага утырып, боланнар белән, котлар өчен яң...

– Сез идарә компаниясеннәнме? Әгәр дә сез су счётчиклары мәсьәләсендә килгән булсагыз, без аны үткән атнада тикшердек... Нәрсәгә мондый маскарад?

– Мин – Кыш бабай! Яңа ел белән котлыйсым килә һәм...

– Сез интернет-магазиннанмы? Белдем? Белдем! Чираттагы яңа әйберегезне тәкъдим итәргә телисезме?

– Мин – Кыш бабай, Великий Устюгтан килдем, котларга телим...

– Ну, ярый, ә Кар кызы кайда? Хәзер шулхәтле күп аферистлар барлыкка килде... Кичә күршебезгә берьюлы өч Кыш бабай керде... Шул арада ул алар белән ләлә-лә – фатирларын үзләренә күчереп язганнар һәм барлык карталарындагы акчаларын алып бетергәннәр...

– Кар кызы аста чаналары белән боланнарны саклый... Сезгә иминлек телим...

– Алайса сез банктан?..

– Барысы да булсын өчен...

– Аңлашылды, кер юу машиналарын ремонтлау, холодильникларны, компьютерларны?

– Барлык гаиләгезгә сәламәтлек...

– Дәваханәдәнмени?

– Өйгә китерүдәнме...

– Белдек, сез супермаркеттан? Сездә акция?

– Яхшы еллар...

– Минә ачыкланды! Турагентстводан икәнсез?

– Яхшы кәефләр...

– Уяулыкны йомшартасыз?

– Бүләккә мин төньяктан чыршы алып килдем!

– Төньяктан? Чыршы? Маша, полициягә шалтырат!..

– Ә хәзер иң зур бүләкне кабул итегез! Тын океандагы утрауга ике атналык ике юллама! Җылынырсыз, кызынырсыз һәм әйләнеп кайтырсыз кышка... Ә миңа тагын биш гаиләгә кереп чыгасы бар, бүләкләр белән шатландырырга. Сау булыгыз!

– Маша, бүләген бүләк, шулай да гардеробтагы пәлтәне, шарфны, бүрекне кара әле...

– Тукта, кызыбыз шалтырата!

– Әни, Кыш бабай килде? Чыршы һәм путёвка алып килгән?

– Алып килгән!

– Димәк, сюрприз уңышлы килеп чыккан! Моны без ирем һәм оныклар белән сезгә Яңа елда бүләк итеп бирәбез!..



Валерий ТАРАСЕНКО



Виктор ФЁДОРОВ



Николай ВОРОНЦОВ



УТЫРЫГЫЗ – «ИКЕ»ЛЕ!

Волгоград өлкәсендә түрәләрнең рус телен белүләрен сынап карарга булганнар. Нәтиҗәләр көтелмәгәнчә булган: 143 катнашучының 43 е диктантны яза алмаган. 100 кешегә бер "биш"ле бар, калганнары көчкә-көчкә "өч"ле һәм "дүрт"легә язганнар. Хәзер төбәктә булган проблемаларга тагын бер проблема өстәлгән. Хезмәт күрсәтүче түрәләр арасында белемсезлекне бетерү өчен чаралар җыелмасы эшләнә башлаган.

ЯХШЫ СӘБӘП

Якутиянең Чернышевский посёлогында кыска вакыт эчендә пенсионерлар өчен ял үзәге төзелгән. Ләкин төзүчеләр вәгъдә ителгән акчаны алмаган. Подрядчик җирле район башлыгы Артём Ширшовка авырлык белән телефон элемтәсенә чыккан, ул, кызганыч, баш бухгалтерның эчкечелеккә бирелүе аркасында түләүләрнең соңга калуы турында хәбәр иткән. Төзүчеләрнең эчкеченең айныганын күпме көткәннәре турында хәбәр ителми.

БРАК ЙОЛА

Улан-Удэ шәһәрендә яшәүче ханым, финанс кыенлыкларыннан арып, интернетта эзотеризм яратучылар төркеменә мөрәҗәгать иткән. Анда аңа 12 мең сумга булышырга булганнар һәм алар ярлылыкка каршы махсус йола үткәргәннәр, аннары бик табышлы инвестицияләр ясап, аның эшләрен яхшыртырга тәкъдим иткәннәр. Соңгы 80 мең сумны сарыф иткәннән соң, ул ритуалның аның өчен бөтенләй эшләмәгәнен аңлаган һәм полициягә мөрәҗәгать иткән.


ИКРА ЭШЕ

Камчаткада 1,5 тонна кызыл икра урлаганнар. Ике билгесез кеше компаниянең бер складына кереп, кыйммәтле деликатес урлаганнар. Сакчы ул вакытта йоклаган. Урланган деликатесның бәясе 12,7 миллион сумга кадәр җиткән. Икра караклары мондый зур урлау өчен 10 елга кадәр иректән мәхрүм ителү яный.

ТАНЫШ КҮРЕНЕШ

Элеккеге Пекин мэры урынбасары Гао Пенг ришвәт алуда шикләнеп, кулга алынган. Рәсми зат рәсми бурычларның гадел үтәлешенә тәэсир итә торган мәҗлесләрдә катнашуда, академик дәрәҗә алуда, өстенлекләр алу өчен кадрлар сайлауда һәм билгеләүдә, законсыз бүләкләр алуда, бәйрәмнәр белән генә шөгыльләнгән, рәсми позициясен дөрес кулланмаган, үз кешеләрен карьера баскычы буенча күтәргән, акчаны кире кайтару өчен контрактлар төзүдә гаепләнгән. Таныш күренеш, шулай бит?







ЭЛЕК ШУЛАЙ, ХӘЗЕР БОЛАЙ...

Хәзер Хуҗа Насретдин дәвере түгел. Без ил хәкименең гел алдын гына күреп торабыз. Арт ягын карамасак та, 10 мең генә түгел, ничә меңнәр оттырганыбызны беләбез. Заманалар үзгәреп тора шул... Безнең Хуҗа Насретдин кебегрәк хәйләкәрлек юк, акыл да, тәвәккәллек тә. Хәтта аның кебек шаярта да алмыйбыз – ярамый.

Шамил МАННАПОВ

БӘХӘС ОСТАСЫ

Беркөнне Ил хакиме Хуҗаны очрата. Сәлам алышканнан соң:

– Син, Хуҗа, юньле-башлы эшләмисең дә, ә үзең җитеш кенә яшисең. Акча каян аласың? – дип бәйләнә.

– Мин бәхәсләшәм дә шунда җиңеп чыгам! Акча отам! – ди Хуҗа.

– Ә минем белән бәхәсләшә аласыңмы соң?

– Нишләп алмаска! – ди Насретдин. – Менә мин әйтәм, синең арт чүмечеңә бер атнадан чуан чыгачак!

– Хи-хи! Ничек инде ул тиктомалдан чуан чыксын икән дә, син аны каян беләсең икән?! Юкны лыгырдама!

Хуҗа чатябыша:

– Ә мин әйтәм – чыга! Ышанмасаң, әйдә бәхәсләшәбез! Ун мең сумнан!

– Әйдә соң, бәхәсләшик, – ди Ил хакиме көлеп. – Артык акчаң бардыр, күрәсең...

Бер атнадан соң, нәкъ сөйләшенгән вакытта Ил хакименең эш бүлмәсенә Хуҗа килеп керә.

– Акчаңны алып килдеңме? – ди Ил хакиме. – Сүзең дөрескә чыкмады бит тәки! Ищщу бәхәсләшкән буласың, дивана!

– Алай булырга тиеш түгел! – ди Хуҗа ышанмыйча. – Каяле, күрсәт арт саныңны.

Ил хакиме, нишләсен, көлә-көлә чалбарын төшереп күрсәтә.

– Каяле, каяле, яктыгарак, тәрәзә янынарак килеп карыйк! – ди Хуҗа. – Бәй, чыкмаган икән шул. Ярый инде, ун мең – синеке!

Ил хакиме гөлдерәп көлә:

– Әлегәчә син минем кебек бәхәсчегә очрамагансың! Башкаларны алдый бир, ә мине төп башына утырта алмассың, шалишь!

– Ялгышасың, Ил хакиме! – ди Хуҗа елмаеп. – Дөрес, мин сиңа ун меңне оттырдым. Әмма үзем аннан күбрәкне оттым.

– Ничек инде оттың?

– Әнә карап бак әле тәрәзәдән. Күрәсеңме анда күпме кеше авызын ачып безгә карап тора! Мин аларга, бүген Ил хакименең арт шәрифен тәрәзәдән күрсәтәм, дип бәхәсләшкән идем. Ышанмадылар. Инде менә хәзер аларның һәркайсы миңа унар мең тиеш!

Алмаз ХӘМЗИН

ӘЙТСӘМ ӘЙТИМ

Яшәлде инде байтак – яшьнәлде,
Шактый эшләр эшләнде.
Җитмеш җиде тулган, сизмәгәнмен
Истә – күзләр яшьләнде.

Утлы йөрәк кайчак утка тыккан,
Суга салган, коткарган.
Гел газаптан тормыш, – дигән –
Җиңүләргә чакырган.

Булсын, булсын, барысы да булсын –
Үксеп-үксеп елаган.
Анда-монда, арасында чыга
Берән-сәрән елмайган.

Ул чаклар да үтте өмет итеп,
Алда, артта – гөлчәчәк.
Менә шундый илдә яшибез лә,
Күрәсез бит ничек шәп!

Исән булу бәхет түгелмени,
Ни җитми тагын безгә?..
Исәнлек ул шактый чамалы хәл –
Ул бары сүздә генә.

Рухи тазалык әллә качканмы,
Кая ул киткән хәзер?
Чын сәнгать кайда бутала,
Адашкан әллә кадер?!.

Үз арада хөрмәт дигән нәрсә
Бар микән бераз гына?
Сәламлибез бер-беребезне бүген
Акчага карап кына.

Әйтсәм әйтим дөп-дөресен сезгә,
Хезмәт хакым унбиш мең.
Белмәмешкә салына җитәкчем, –
Яннарымнан үтә тиз – ичмасам,
Ник хәлем белсен бер көн...



Вячеслав ШИЛОВ



Виталий ПОДВИЦКИЙ

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, популяр фокус остасы – Альберт Гаделнең истәлекләр дәфтәреннән...

БЕРАЗ ГЫНА ИШЕТМИ

Сугыштан соңгы еллар. Филармония артистлары районнарда гастрольдә йөриләр. Болай да ачлы-туклы яшәгән халык, авырсынып, кесәсенә карап кына концертка баралар. Күбрәк концертларны "хәллерәк" колхоз рәисләре "гарантиягә алып", колхозчыларга "бушлай" концерт күрсәтә иде. Сирәк кешедә генә гади радиоалгычтан башка, күңел ачарлык әйбер юк. Ул заманда телевизор дигән "әкәмәт, искитмәле тартманы" күрүче түгел, ишетә белүче дә юк иде.

Усман ага Әлмиев тә катнашкан концерт бригадасы бу. Әле алар яшь артистлар. Араларында курайчы Хәмит ага Бакиров та була (танылган күренекле композитор Әнвәр Бакировның абыйсы).

Хәмит абый тыныч холыклы, буйга-сынга уртача буйлы, бик "скромно" киенеп йөри иде. Мескенемнең колаклары начар ишетә башлый. Ул авыру музыкант өчен "приговор" дигәндәй, бик борчыла...

Артистлары да "явызлар" – "ради хохмы" дигәндәй, аңа:

– Хәмит, Усман сине чукрак, берни ишетми дип, кешеләр алдында хурлады, гайбәт сүзләре ишеттерә, дигән.

Шушы сүзләр Хәмит абыйның "авырткан җиренә" баса. Клубта, әле тамашачылар килгәнче, артистлар үзләре генә вакытта Хәмит ага "шартлардай" булып Усман абыйга ябырыла:

– Син, Усман, мине чукрак дип хурлап йөрисең икән, – дип кызып китеп, янында торган урындыкны тибеп аудара.

– Усман абый хәйләкәр, бераз шүрләүчәнрәк кеше иде. Югалып калмый:

– Ю-ю-юк, Хәмит, бу дошман сүзләре. Мин сине чукрак димәдем, бераз гына колагы ишетми, дидем, – ди дә, тиз генә урамга, саф һава "суларга" чыгып китә...

Икенче көнне арбаларга җигелгән колхоз атларына төялеп, аларны икенче авылга илтеп куя.

Хәмит абый, ашык-пошык әйберләрен җыеп, арбадан урын алырга ашыга.

"Барасы" авылларында фатирларга урнашкач, Хәмит абый юл сумкасында шикәр салган кечкенә янчыгын тапмый. Нишләргә? Кан басымы күтәрелә...


Вак-вак кисәкләргә вакланган, бер айга җитмәсә дә, шикәрсез чәй эчәргә туры киләчәк бит... Бәла өстенә бәла дигәндәй, такта чәй төреп салган янчыгы да юк.

Теге авылда, ашыгып җыенганда самовар артында онытылып калган, "шайтан шомлыгы..."

Хәмит ага, ут капкандай, колхоз идарәсенә барып, телефоннан әле генә килгән авыл рәисенә шалтырата. Елардай булып, мескен тавыш белән үтенеп сорый: зинһар, берәрсе артыннан аның шикәр янчыгы белән такта чәен җибәр инде дип, кемдә фатирда булуын да әйтә.


Колхоз рәисе мәрхәмәтле кеше булгандыр. Сөйләп тә, язып та ышанмаслык хәл. Берничә сәгать узгач, күрше авылдан, атка атланган егет Хәмит абыйның чәен, шикәрен клуб мөдиренә китереп тапшыра.

Үз чиратында, клуб мөдире Хәмит абыйга илтеп биреп, аны чиксез шатландырып, инсульттан саклап кала.



– Якын Көнчыгышка демократия кертергә әзер!

Эрнст ГЕЛЬМС, 1953 ел.



Иосиф БОБРОВИЦКИЙ, 1963 ел.



• • •

Урманда ярты ел нәҗитәләре буенча премияләр бүлделәр, һәм кайнар бәхәсләр, килешүләрдән соң мондый фикергә килделәр: аюга көчле булган өчен, бүрегә ныклыгы өчен, төлкенең хәйләкәрлегенә, куянның батырлыгына. Һәм ала көзәнгә... сасы ис таратып йөрмәсенгә.

• • •

Ирләр колагына: хатыныгыз белән ызгышырга керешкәнче, ике-өч тапкыр уйлагыз: 10–15 минуттан соң бит сезгә ызгышу туйдырачак, ә аңа – юк.

• • •

Аракыга бәяне нигә күтәрәләр – кешеләр азрак эчсеннәр өчен, ә тәмәкегә – азрак тартсыннар өчен. Ә ни өчен коммуналь хезмәт күрсәтү бәясен күтәрәләр икән соң?

• • •

– Кичә безнең начальник офис мәчесен куып чыгарды.

– Нигә?

– Имеш, ул аның урынына күз аткан.

• • •

Ябыгырга телисезме? Яшел чәй эчегез – аена 5 кг юк. Яшел кофе эчсәгез – бер айга 8 кг минус. Яшел колбаса ашап карагыз! Тәүлек эчендә 10 кг югалтырсыз!

• • •

– Санта-Клаусның чынлыгына ышанасызмы?

– Санта-Клаус юк ул! Моны миңа Кыш бабай әйтте.

• • •

– Корпоратив ничек үтте?

– Яхшы. Истә калырлык хәлләр булды. Ә синдә?

– Шулай ук яхшы. Әйе, әмма аларны искә төшермәү хәерлерәк.

• • •

Кияүдәге хатыннар өч төргә бүленә: берәүләр бернинди дә ирләрне кызыксындырмый торганы; икенчеләре үзләренең ирләрен генә кызыксындыра торганнары; өченчеләре кияүдәге килеш чит-ят ирләрнең дә күңеленә хуш килгәннәре!

• • •

– Проблемаларың бар идеме?.


– Аларны ничек чиштең?

– Кредит алдым. Шуны аңладым: элек проблемаларым булмаган икән.

Александр АЛЁШИН



Валентин ДУБИНИН



Валерий ТАРАСЕНКО





УРМАН ҺАВАСЫНА ҺӨҖҮМ

Кадерле "Чаян". Татарстанның Яшел Үзән районындагы Идел-Кама тыюлыгы күпләребезгә дәва, тынычлык бирүче табигый зона һәм уникаль Идел буе экосистемаларына сыеныр урын тәэмин итүче булса да, эшмәкәрләрне тынычландырмый. Чөнки монда алар өчен "алтын" катламы табылган – гаять калын ком запасы. Берничә ел элек инде карьер ачып, казу эшләре дә башланган булган икән. Ул вакытта бу тирәдә яшәүчеләр зур кыенлык белән әлеге кадерле табигатьне саклап кала алганнар. Менә тагын Бело-Безводное белән Малые Ключи арасында һәм Сумка елгачыгы тирәсен чираттагы коммерсант, эшкәртергә маташып, үзенең экскаваторларын китереп куйган.

Бу юлы "ком генераллары" белән көрәшкә монда яшәүче халык һәм Республикабызның Минэкология галимнәре дә күтәрелде. Инде ком эшен башлау тыюлыкка зур зарар китерәчәге дә расланды: күлләр кибәчәк, инешләр, җәнлекләр һәм кошлар бетәчәк. Әле тагын уникаль урман: 20 километрга сузылган тыюлык, ылыслы һәм яфраклы агачлар.

Күптән түгел Республиканың Арбитраж суды төзелеш өчен кирәк комны шул җирдән тәкъдим итте. Бу карарны тыюлык саклаучылар, әлбәттә, кире кагарлар. Чөнки аларга озакламый саф урман һавасын кондиционер шешәсендәге кер юу сыекчасын иснәп кенә рәхәтләнергә туры килер.

Яшел Үзән районының Бело-Безводное һәм Малые Ключи авылында яшәүчеләр.

ИНТЕГҮ


Хөрмәтле редакция! "Яхшыга юраган идек, ләкин киресенчә килеп чыкты" дигән әйтем юл хәлен тулысынча тасвирлый. Бу очракка Зәкиев урамының 20 нче һәм 24 нче йортларында яшәүчеләр тап булды. Юл идарәчеләре Вознесенский трактында дублёр юл ясап куйдылар. Бу вакыйгага без бик шатланып торган идек, хәрәкәт куркынычсызлыкка әверелер дип.

Кемнәргәдер бу шулай килеп чыккандыр, ләкин бу йортларда яшәүчеләр өчен түгел. Ишегалдыннан чыгып китү күпкә кыенлашты. Дублёр юлдан Глушко урамына чыгучы автомобильләргә көйләнелә торган урам чатында туктап торырга туры килә – ул монда яшәүчеләргә керү һәм чыгу хәрәкәтен кыенлаштыра. Төрле манёврлар ясап оятсызланырга, боргаланырга-сыргаланырга, клаксонга басып кычкыртырга – шунсыз теләгән җиреңә үтеп булмый чөнки. Юл хезмәткәрләренә бу четереклекне чишү өчен үзебезнең фикерләрне дә әйтеп карадык, ягъни тагын бер дублёр юл салырга – ишегалдыныкын, шуннан урам чатына туп-туры чыгарга. Аңа акча да күп кирәкми инде – ерак ара түгел. Ләкин безнең киңәш үтмәде. Кызганыч, проекттагы ялгышлыклар аркасында халык кыенлык күрә.

Зәкиев урамындагы 20, 24 нче йортларда яшәүчеләр.
КАЗАН

ВАЛЕРИЙ ТАРАСЕНКО ЕЛАННАРЫ









Ул 1899 елның 29 декабрендә Уфа губернасы Златоуст өязе (хәзерге Башкортстанның Салават районы) Малаяз авылында Сиражетдин мулла һәм Таибә абыстай гаиләсендә туган.

1910 елдан Уфада «Хөсәения» һәм «Галия» мәдрәсәләрендә укый. Шул чакта ук шигырьләр яза башлый. 1914–1916 елларда, Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда, поэма һәм драма әсәрләре басылып чыга.

Нәкый Исәнбәт туган якларындагы Атау, Тастүбә, Үрге Кыйгы мәктәпләрендә татар телен укыта, халык авыз иҗатын җыю белән шөгыльләнә.

1920–1922 елларда, укытучылык эшеннән аерылмыйча, Уфа халык мәгарифе институтында һәм Харьков университетының халык мәгарифе факультетында укый.

Нәкый Исәнбәт – тел галиме дә. Күп еллар дәвамында татар теленең фразеологик байлыгын җыйнап, сүзлек итеп бастырды.

Аның «Уракчы кыз», «Бормалы су», «Гармунчы егет», «Син сазыңны уйнадың» кебек күп кенә шигырьләре җыр булып яңгырый.

Романтик-оптимистик рухлы шигырьләр, сәхнә жанрында иҗат ителгән сатирик комедияләр, көндәлек матбугатта басыла килгән публицистик мәкаләләр, фельетоннар – болар һәммәсе Исәнбәтне 1920 еллар татар әдәбиятының күренекле вәкиле итеп танытталар.

Нәкый Исәнбәт күпсанлы драма әсәрләрендә тегe яисә бу чорга караган вакыйгалар яктылыгында халыкның тарихын, гореф-гадәтләрен тирәннән сурәтли: «Хуҗа Насретдин», «Җирән Чичән һәм Карачәч сылу», «Миркәй белән Айсылу», «Гөлҗамал», «Мулланур Вахитов», «Муса Җәлил» әсәрләре – шундыйлар. Ул оста тәрҗемәче буларак та танылды, А. С. Пушкин, Мольер, Низами, Шекспир әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте.

Туган әдәбияты, мәдәнияте һәм сәнгате өлкәсендәге игелекле хезмәтләре өчен Нәкый Исәнбәткә Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге һәм Татарстанның Халык язучысы дигән исем бирелде.

Татар халкының рухи тормышында, сәнгать һәм әдәбиятында Нәкый Исәнбәт иҗаты күренекле урын алып тора.

Нәкый Исәнбәт 1992 елның 12 сентябрендә Казанда вафат була.

СИН САЗЫҢНЫ УЙНАДЫҢ

Моңланып ай нурларында
Син сазыңны уйнадың;
Нинди кыллар чиртте, бәгырем,
Ул матур, яшь кулларың?

Бакчаның бер почмагында
Мин утырдым, тыңладым;
Тыңладым да мин ирексез
Яшьлегемне уйладым.

Уйладым мин яшьлегемне,
Син сазыңны уйнадың!

Кайгылы күңлем тавында
Яңгырады кылларың;
Яңрады ул моңлы кыллар...
Син сазыңны уйнадың.

Чыңлаган шул кылларыңдай,
Бер-бер үтте елларым;
Үтте айлар, үтте еллар
Түзмәдем мин, егъладым.

Үтте айлар, үтте еллар,
Син сазыңны уйнадың!

Үткән ул даулы гомерләр,
Кан-көрәштә яңгырап,
Саклаганмын тик күңелдә
Шул көрәшнең моңнарын.

Аһ, терелттең син күңелнең
Бар күмелгән кылларын!
Яңрап үткән ул гомернең
Мин авазын тыңладым.

Яңгырап үтте гомерләр,
Син сазыңны уйнадың!

ГЫЙСЪЯН ҖЫРЫ

Нык аякларны басып киң,
Канлы күкрәк өстеңә,
Ишетәсеңме, әй Җир-ана,
Антлар орам мин сиңа!

Кол булып чүккән тезем аргач,
Менә тордым да мин,
Җилкәм өстеннән олактырдым
Тәхет-таҗ, шаннарын!..
Өстеңә бәрдем бөтен
Зынҗырларын кырдым да мин!

Төн. Офыкта – янган утлар.
Тау ватам мин, юл йөрим;
Атлыгам мин зур җиңүнең
Тәхтенә, әй Җир шары!
Бер дә шиксез, иң җитез
Арбам булырсың син минем!

Кулда – тукмак. Нык аякларны
Басып җир өстенә,
Иштәсеңме, әй Күк-ата,
Антлар орам мин сиңа!

Ут ягып, көн-төн шулай
Гыйфрит кебек мин эшлимен.
Зур чүкечләрне сугам да
Кычкырам: әй Күк йөзе!
Бер дә шиксез, таң белән
Хуҗаң булырмын синең!

Шанлы юл алган юлым, әй Күк!
Барамын мин сиңа!
Канлы арбамда синең
Аллаң булырга мин барам!
Ат итеп аркаң иярлим,
Инде менәм өстеңә!

ҖӘЙГЕ ТӨН

Нинди салкын, җанга рәхәт,
Нинди ямьле җәйге төн;
Таулар, урманнар, болыннар
Нинди серле, нинди тын.

Ай йөзә күк гөмбәзендә,
Тын, бәхетле елмаеп,
Күк йөзен күксел көмештәй
Бер гаҗәп нурга манып.

Шәүлә төшкән күк битендә,
Су кереп, ай ялтырый.
Тибрәнә җем-җем күл өсте –
Нур эчендә калтырый.

Балкый йолдызлар бәхетле
Киң, ерак күктән торып;
Котлый бар да җәйге төнне
Бер тонып, бер яктырып!

АККОШ

Туганлының тып-тын күлендә
Кояш ята көлеп төбендә,
Күл өстенә төшкән күк өстендә
Аккош йөзеп бара тын гына.

Муеннары айдай уелган,
Агып төшкән судай коелган,
Коелып-чәчелеп киткән шул су кебек,
Канатлары өскә кыелган.

УРМАН САГЫШЫ

Караңгы урман, коңгырт нарат
Уралып үскән Урал-тау буенда,
Шау-шулы авыл, илдән ерак
Бер өй утыра шул урман куйнында.

Иске дә иске, һай, түбәсе,
Еллар үтеп кыеклар иелгән;
Какмый да какмый бер яфрагын
Тәрәзәгә баш иган карт имән.

Чыгадыр шунда кич бер карчык,
Тынып утыра бусага төбендә;
Күз алда үскән умырзая
Әкрен сөйли үткәнне күңелдә

Рөстәм ЗАРИПОВ

ТӨШ

Ялганчы тарихчыларны ялган акча ясаучыларга
тиеш җәзага тартасы иде...
СЕРВАНТЕС, испан язучысы

Әдәбиятчы кабахәтләрдән дә җирәнгечрәк
башка берни белмим.
ВОЛЬТЕР , француз философы

Мин төш күрдем, имеш, трибунага менеп, язучылар җыенында нотык тотам: Тамагым карлыгып китсә, аптырамыйм, стаканнан голт-голт "Шифалы су" йотам.

Сөйлим, матди ярдәм алып, Россияне "П---россия" , дип атап китап язсаң, әдәби журналда да шуны бастырып,гонорарларга коену җаен тапсаң, армиядә бер көн хезмәт итми генә армиядәге тормышка тел тидерсәң,шундый иҗат өчен хөкүмәтебезнең төрле-төрле бүләкләренә тиенсәң,нишләсәң дә номер үтә, дип куанып,шатлыктан арт шәрифеңне чәбәкләсәң,шигырен җыр куеныннан йолкып ташлап, фронтовик шагыйрь рухын яңакласаң, депутат булып сайланып мандатлансаң,кала үзәгендә кәттә фатир алсаң,ә язганың үзгә халык авторлары әсәрләре сюжетларын кабатласа, текә түрә ханым сиңа гашыйк булса, һәр бәйгедә өчәр премия сонса яки түрәләр башмагын ялап арысаң, нәсел ыруларын данлап роман язсаң,тарихка керү өчен бу уңай булыр,яшьләр өчен мондый үрнәк кулай булыр!

...Такылдавым шул урынында кырт бүленә. Дәвамлы, көчле алкышларга күмелә....

...Баксаң, түрәбез докладны тәмам икән, кул чабулар миңа түгел, аңа икән.

Татлы йокымнан айнырга туры килә, ава-түнә атлап, кайтып китәм өйгә.

КАЛӘМЗАТЛАРЫМЫЗ

Берсеннән-берсе канәгать кыяфәтләр, бар да маһир уздырырга зыяфәтләр...Такылдарга мөнбәрләрдән шуларга куш. Язганнарының бәясе – тишек грош....

Буш китапханәләргә таба титаклады дәүләт хисабына чыккан китаплары. Үтмәс товарларга "бәйге" шунда үтә, җиңүчене биш йөз мең сум бүләк көтә.... "Туган ягым" җырының сүзләрен бутап, рәнҗесә рәнҗер Рамазан агабыз, дип, 182 шигырь кемнәр язды, 200 мең тәңкә бүләк алабыз дип?!. Мәрхүмнең рухи милкенә тукынуга юл ачучы затлар һаман тотмый җавап,ямьсез ният һәм гамәлгә нокта кую барып чыкса, күкләр язар иде савап... Татарның бөек затларын күтәрәм дип, дүртәр йөз мең сум акчаны кемнәр состы? Язмый гына алганнарын сеңдергәннәр кая посты, әйтегезче, пажалысты!

Тапшырган әсәрләргә кем бәя куйды? Шул хакка торырлыгын кем исбат итте?

Мәскәүдән комиссия көтәсе микән җәлеп итү өчен бәйсез экспертны...

Тукай бүләгенә шактый озын чират, кайберләрен аннан йолкып ала зират. Терсәкләр тырпаюлы, ә баш-күз тонган. "Миңа! Миңа!" – дип даулашу – уңнан сулдан...

Әдәбият үстерергә! Сылтау шундый... Дәүләт юмарт, күп төр премия бирә... Талантлылар, яшь җилкенчәкләр "боз ялый", сәмәнне үтә тиз ялмый тар даирә... Рәис булу – зур нигъмәт, идарәгә үтүнең дә хикмәте бар... Түбәннән калыккан кенәз – каләмзатның шактый калын май ягылган икмәге бар... Шушыларммы халкыбызның горурлыгы? Акылы һәм намусы, дип торырлыгы?.. Күз карасыдай ыъшыклап җан сафлыгын шулар кайгыртамы милләт йөз аклыгын?..

Рифкать ИБРАҺИМ

Байлык

Эшләп баеган байлар бар,
Бар урлап баеганы.
Хәрам белән баеганның
Хәләл дип алдаганы.

Бездә дә күп, Үзәктә дә
Аларның фатирлары.
Чит илләрдә яхталары,
Зиннәтле виллалары.

Милләт җанлы булмаганнар
Халкы өчен борчылмас.
Милләте телсез калса да,
Ризасызлыгы тумас.

Миллилеге беткән байның
Дуслары булыр микән?
Халкына хезмәт итмәгәч,
Телгә алыныр микән?

Талап, алдап җыйган малның
Кадере калмас аның.
Үзе киткәч, бер утырып
Сатып эчәрләр малын.

Шул бәндәне соңгы юлга
Озатучы булырмы?
Аның гомерлек йортына
Сукмак – юл сугылырмы?






ЧАЯН
САТИРА ҺӘМ
ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 12 (1949) декабрь 2024
Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.
420047, Татарстан Республикасы,
Казан, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан,
Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.12.2024 ел.
Тираж – 1906 Заказ А-2834
Редакциянең адресы: 420066,
Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.tatar
Бәясе ирекле
16+

Уйна да, уйла да!







1. Оптимист реалисттан нәрсәсе белән үзгә?

2. Нәрсә ул хезмәт хакы?

3. Нәрсә ул сувенир?

4. Елның иң тыныч вакыты?

5. Урманда компасың булмыйча адашсаң, нишләргә?

6. Үзара сөйләшкәндә балагыз тыңламаса, нишләр идегез?

ҖАВАПЛАР

1. Оптимист бәхет эзләп йөргәндә, реалист аны акчалата алган була. 2. Урлый алмаучыларга матери-аль ярдәм. 3. Үзегезнең шәһәрдә беркайчан да сатып алмыйча, башка җирдән юнәткән товар. 4. 1 гыйнвар көненең беренче яртысындагы вакыт: җәяүлеләр дә күренми, бөкеләр дә юк. 5. Көз килгәнен көтәргә – кошлар көньякка очачак. 6. Нәкъ үзләренә әйткәнегезне белдергән кыяфәт чыгарагыз.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 11 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«БЕЗ КАБЫЗГАН УТЛАР».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан).

Җиңүчебез – Казаннан

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ

ЯҢА ЕЛ ҖЕМЕЛДЕКЛӘРЕ



Виктор ФЁДОРОВ


Виктор БОГОРАД


Максим СМАГИН

Туп-тулы тартма кишер күреп, Кар кешесе авыр сулап куйды: “Күпме безнекеләр әрәм булган!”

Ярлы гаиләдә үскән Кар кешесе гомере буе тишек чиләк киде.

Яз табигатькә җан җылысы өреп, аннан хәтта Кар кешесе дә эреп китә.

Кар кешесе бәйрәмнәргә һәрвакыт Кар кызы белән йөри иде, ә карчыгы ялгызы гына аның кайтышына кар кабартмалары әзерләп көтә.

Евгений ОБУХОВ



Валентин ДУБИНИН



Анастасия ВАСИЛЬЕВА